№1

Чыгу көне: 30.09.2021



Белем көне - ул чәчәкләр һәм ак тасмалар бәйрәме. Бу көнне һәр укучы, чәчәк бәйләме тотып, уку йортына ашыга. Күпләр бу бәйрәмне "Беренче кыңгырау" бәйрәме дип тә йөртәләр, чөнки нәкъ менә бу көнне мәктәп балалар бакчасыннан килгән "яңа" укучыларын каршы ала. Ап-ак тасма бәйләгән, кулларына кечкенә портфель

тоткан укучылар беренче тапкыр белем йорты бусагасын атлап керә, беренче укытучылары белән очраша, беренче кыңгырау тавышын ишетә.

1нче сентябрь рәсми рәвештә "Белем көне" дип беренче тапкыр 1984нче елда игълан ителә. Бу көнне һәр укучы бәйрәм итә. Шулай да "Белем бәйрәме"н беренче сыйныфка баручылар аерым бер дулкынлану белән көтеп алалар.

Быел 1 нче сентябрь көне бик матур, кояшлы иде.

Кулларына чәчәк бәйләмнәре тоткан укучылар мәктәпкә юнәлделәр.

Иң беренче мәртәбә укырга килүче 1 нче сыйныф укучылары өчен бу көн икеләтә шатлыклы иде, чөнки алар балалар бакчасы белән саубуллашып, белем дөньясына атлыйлар...

Бәйрәм бик күңелле узды.

Беренчеләр абый-апаларын шигырьләр сөйләп куандырды. Чыгарылыш сыйныф егет-кызлары да үзләренең алмашларына хәерле юл теләп, символик белем ачкычы тапшырды. Яңа уку елы башлануын хәбәр итеп яңгыраган кыңгыраудан соң классларда тынычлык дәресләре узды.

Мәктәп, син бит төп йортыбыз,
Күңел сиңа тартыла.
Бүген бөтен ил баласы
Мәктәпләргә агыла.
Каршы алыр укытучы,
Каршылар сыйныфташлар.
Көмеш авазлы кыңгырау
Тәүге дәресне башлар.




Хәерле, уңышлы уку еллары Сезгә, укучылар!

Газета хәбәрчеләре

**Бу чыгарылышта:**

| | |
|---|---|
| Бу нәрсәдән башланды? | 1 |
| Актуаль әңгәмә | 2-4 |

**Игътибар итегез!**

- Каникуллар артта калды.
- Укучылар, тырышып укыгыз, укытучыларны тыңлагыз, өй эшләрен һәрвакыт әзерләп килегез!



Мәктәбебез өчен борчылып торучы, белем бирү, оештыру эшләрен алып баручы, гомумән, мәктәп тормышында иң җаваплы кеше кем дип уйлыйсыз?

Әлбәттә , мәктәп директоры– Динә Альбертовна. Бүген без аның белән әңгәмә үткәрдек.

Безнең укучыларыбызга бу бик әһәмиятле булыр, дип уйлыйм, Сез директор булып эшли башлавыгыз турында берничә сүз әйтә алмыйсызмы?

Д.А. Беркайчан да үземне директор булып эшләрмен, дип уйламый идем. Башта мин укытучы булып эшләдем, 2 елдан соң директор урынбасары булдым,шуннан сон миңа директор урынын тәкъдим иттеләр. Сездән бар да чыгачак, сез булдырачаксыз, диделәр.

Сез балачакта кем булырга теләдегез?

Балачакта кем булырга теләгәнмендер, әйтә алмыйм,этием–инженер, әнием укытучы иде. Мин әниемнең хезмәтен күреп, беркайчан да укытучы булмамын, дидем. Мин җиңел сәнәгатька укырга кердем. Училище тәмамалап, 5 нче дәрәҗәгә ия булдым, аннары университетка кердем, инженер-технолог булдым. Үзгәртеп кору еллары иде, мине модель йортына модельер булып чакырдылар,аннары хезмәт укытучысы булып килдем,Укытучы буларак, 2 нче югары белем алдым, менеджмент буенча укыдым.

Сезнең дипломнарыгыз күптер инде...

Әлбәттә, аларны санап бетерерлек түгел. Директор буларак,3 елга бер белемебезне тирәнәйтәбез.

Укучыларыбызның, укытучыларыбызның грамоталары да мәктәп өчен зур уңышлар китерә.

Коллективны оештыру өчен, нинди эшләр башкарасыз?

Укытучылар, директор урынбасарлары һәрвакыт бердәм булырга тиеш. Бердәм булып эшләгәндә генә, коллективта бердәмлек, дуслык булачак.

Мәктәбебездә укытучыларны берләштерү максатыннан, төрле экскурсияләр оештырабыз, быел гаиләләр, дуслар белән Түбән Новгородка барып кайттык.

Профкомыбыз бик яхшы эшли. Туган көннәрне онытмыйча, төркемебездә котлау сүзләре җибәрә.

Быел, “Укытучылар көне”ндә,укытучыларны бызга, һәр елдагыча, грамота бирәчәкбез.

Мәктәп укучыларда нинди сыйфатларны үстерә?

Тышкы кыяфәт, төпле белем алу...

Безнең теләгебез: укучыларыбыз төрле түгәрәкләргә йөреп, үз өстендә эшләсеннәр, төрле яктан камил, сабыр булсыннар, һәрвакыт сүзләрен уйлап сөйләсеннәр, бер-берсен хөрмәт итсеннәр. Без аларга һәрвакыт ярдәм итәргә әзер.

Әңгәмәгез өчен бик зур рәхмәт!

Җаваплы эшегездә зур уңышлар телибез!

Соколова София

Әле күптән түгел генә Динә Альбертовна тагын бер мактаулы РФ грамотасына ия булды.

Без директорыбызны чын күңелдән котлыйбыз, иҗади уңышлар телибез!

# Актуаль әңгәмә

Бүген без тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Гөлнара Миннегали кызы белән әңгәмә үткәрдек. Ул безне мәктәптә уздырылачак чаралар белән таныштырды.

Г.М. Бу уку елында да үткән елдагы бәйгеләр, ярышлар уздырылачак. “Хор ярышы», “9 май”, “Тезелү маршы” һ.б.

Яңа ел бәйрәме уздырылачакмы?

Г.Д.: Әлегә Яңа ел бәйрәме турында төгәл генә әйтә алмыйбыз. Шулай да мәктәп бизәләчәк, чыршы куелачак, мәктәбебездә яңа ел кәефе булачак.

Югары сыйныф укучылары белән «Үзидарә көне» дә уздырылачак.

Кәгазь җыю, китап бүләк итү, барысы да булачак.

-Димәк, барлык чаралар да уздырылачак?

Әлбәттә, бу чаралар булу сыйныфташларны, эти-әниләрне берләштерә.

Бәйгеләрдә, чараларда катнашып, җиңүчеләр кубок алалар.

-Гөлнара Миннегалиевна, укучыларга нинди киңәшләр бирер идегез?

.Д.: «Укучылар тырышып укысыннар, тәртипле, сәламәт булсыннар иде. Сәламәтлек – зур байлык. Аны сакласыннар иде. Начар гадәтләрдән саклансыннар, әгәр андыйлар булса, андый

укучыларны бу гадәтләреннән арындырсыннар иде. Әлбәттә, югары сыйныф укучылары да андый укучыларны күрсәләр, туктатып, үгет-нәсыйхәтләрен бирсә иде».

Соколова София



**Реклама хокукларында... :-)**

Безнең мәктәптә нинди генә түгәрәкләр эшләп килми?! Күңелең кайсын тели, шуны сайлап ала аласың. Шулардан спорт секциясенә караганнарын гына алыйк: волейбол, баскетбол, гимнастика.

Болар әле барысы да түгел, иң күпләр теләп йөргәннәре генә.

Театр түгәрәге, 2 телдә чыгып бара торган газета түгәрәге, шахмат, робототехника, инглиз теле, спорт секцияләре, тагын әллә никадәрле түгәрәкләр эшли бездә.

Әгәр дә Сез түгәрәкләр белән кызыксынгансыз икән, 102 нче кабинетка килеп, языла аласыз.

Барыгыз да рәхим итегез!

# Беренче тапкыр 5 нче сыйныфка

«Беренче тапкыр беренче сыйныфка».

Кайчандыр мин дә беренче сыйныф укучысы идем.

Кулларыма зур чәчәк бәйләмнәре тотып, иң беренче мәртәбә мәктәп бусагасын атлап кергән идем.

Без шундый кечкенә, шундый таянычсыз идек…

Беренче сыйныфка әзерләнү шатлыклы да, шул ук ваккытта куркыта да иде…

Мәктәптә мине беренче укытучым каршы алды. Аның мөлаем елмаеп исәнләшүе миндә ышаныч уятып, күңелемне тынычландырды.

Быел мин 5 нче сыйныфка килдем. Башлангыч сыйныф белән саубуллашып, урта сыйныфка «аяк бастым».

Мин яхшы укырга, төпле белем алырга сүз бирәм.

**Матренина Сафина**

**5 «г» Кл.**



# Актуаль әңгәмә

Актуаль әңгәмә

Без көн дә иртән мәктәпкә киләбез дә, укып, түгәрәкләргә йөреп, кич җиткәч кенә кайтып китәбез. Һәр көнне безне елмаеп каршы алып,

безне саклап торучыларны күрәбезме соң без? Алар тәртип саклап, югалган әйберләребезне табарга булышучы да бит әле. Бүген без аларның берсе турында язарга булдык. Ул безнең гәҗитебезнең сорауларына җавап бирергә ризалыгын белдерде.

Ул — Нина Анатольевна.

Сез безнең мәктәптә күптән эшлисезме? Белемегез нинди?

Минем белемем -урта, тимер юлда эшләдем. Хәзерге вакытта лаеклы ялда. Бу мәктәптә эшләвемә әле 1 ай гына.

Элекке эш урыныгыз искә төшеп сагындырмыймы?

Мин монда балалар белән аралашам. Миңа бик күңелле. Җанлы тормыш.

Мәктәптә эшләвегезгә ничек карыйсыз ? Монда бит бик тынгысыз: балалар кычкыра, шау—гөр килә...

Бу бит балалар. Алар шаулашырга тиеш инде. Без дә бит шундый ук шук идек.

Мәктәптә укучылар бик еш кына әйберләрен югалта, тапкан әйберләрне Сезгә китереп бирәләрме?

Әйе, укучылар әйберләрен еш югалталар, кайберләре югалткан әйберләрне табып, безгә китереп бирә.

Димәк, алар сезгә ышаналар.

Сезнең укучыларга теләкләрегез нинди?

Әйе, алар безгә ышаналар, бу безне шатландыра.

Укучыларга теләкләрем: олы кешеләрне хөрмәт итсеннәр, транспортта урын бирсеннәр, исәнләшергә онытмасыннар иде…

Сезгә безне кайгыртуыгыз, безне саклавыгыз өчен зур рәхмәт!

Балалар! Игътибар итегез әле, нинди ягымлы, ышанычлы кешеләр безнең әйләнә—тирәбездә. Аларны хөрмәт итик!

Курняева Юлия

Редакциянең адресы:

420101, Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576

Тираж – 50 экз.

Баш мөхәррир
һәм дизайнер:
Габдуллаҗанова А.Ф.

Редколлегия әгъзалары:
Сафина Камилла, Соколова София, Овезова Ләйлә, Курняева Юлия